**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 4-35-01, 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02.2024 **Чирмешән авылы** № 9

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районында
бала туу уңаеннан бер мәртәбә
түләү турында

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында балалар туу буенча чаралар белән гаиләләрне кызыксындыру максатларында **КАРАР БИРӘМ:**

1. Бала туу уңаеннан 30 000 (утыз мең) сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләү тәртибе турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Баланың туу уңаеннан бер мәртәбә түләнә торган түләү бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Р.Т.Айбатов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башлыгы карарына
1 нче кушымта
01.02.2024 № 9

Бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган
түләү бирү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы 30 000 (утыз мең) сум тәшкил итә (Физик затларның керемнәренә салымны исәпкә алмыйча).

3.Бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләү Татарстан Республикасының Чирмешән муниципаль районында теркәлгән һәм яшәүче, шулай ук район территориясендә даими эш урыны булган, бала тапкан хатынга яки баланың атасына (опекунына) бирелә.

Күп балалы йөклелек вакытында бер тапкыр бирелә торган түләү һәр балага бирелә.

Үле туган бала өчен түләү түләнми.

Хатын-кыз үлсә, ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителсә (ата-ана хокукларында чикләүләр) бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләү баланың әтисенә (опекунына) бирелә.

4. Бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләү балалары тулы дәүләт тәэмин итүендә булган гражданнарга, шулай ук ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән яки ата-ана хокукларында чикләнгән гражданнарга билгеләнми.

## II. Бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү һәм түләү тәртибе

5. Бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле затлар (алга таба - гариза бирүчеләр) Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә түбәндәге документларны тапшыралар:

- район Башлыгы исеменә бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында гариза;
- паспорт күчермәсе (барлык битләр);

- бала (балалар) туу турындагы таныклыкның күчермәсе;
- әнинең үлем таныклыгының күчермәсе - үлем акты теркәлгән очракта;
- эш урынынннан белешмә;
- банк реквизитлары;
- вәкаләтле зат өчен ышаныч кәгазе күчермәсе;
- мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә даими яшәү фактын раслаучы һәм гаилә составы турында җирле үзидарә органы белешмәсе.

Документларның күчермәләре оригиналлар күрсәтелеп тапшырыла һәм бүлек белгече тарафыннан раслана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа кушылган документлар күчермәләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланырга тиеш.

6. Эшләр идарәчесе гаризаны теркәгән көннән алып ун эш көне эчендә барлык кирәкле документлар белән бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләү мәсьәләләрен карау буенча Комиссия каравына чыгара (алга таба – Комиссия).

Комиссия бала туган очракта бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысул белән (смс-хәбәр, электрон почта) гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Бер тапкыр бирелә торган түләү Сертификат рәвешендә рәсмиләштерелә һәм гариза бирүчегә тантаналы рәвештә тапшырыла.

Комиссия карары гариза бирүченең исәп-хисап счетына бер тапкыр бирелә торган түләүне исәпкә алу өчен бухгалтериягә җибәрелә.

7. Бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып, булган мәгълүматлар һәм документлар җыелмасы нигезендә аны алу хокукы булмавы тора.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

8. Гариза бирүче тапшырылган мәгълүматның дөреслеге, шулай ук алар булган документларның чынлыгы өчен җаваплы.

9. Комиссия гариза бирүчеләр биргән мәгълүматларга бирелгән вәкаләтләр чикләрендә өстәмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

10. Эшләр идарәчесе бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләү алучыларның шәхси эшләрен формалаштыра һәм саклый.

11. Бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган түләү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башлыгы карарына
2 нче кушымта
01.02.2024 № 9

Бала туу уңаеннан
бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү мәсьәләләрен карау буенча
комиссия составы

| | |
|---|---|
| Гомәрова Надежда Габдрәшит кызы | район Башлыгы урынбасары, район Советы рәисе урынбасары – комиссия рәисе |
| Моксинова Ләйләгөл Вәгыйз кызы | район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - комиссия рәисе урынбасары |
| Хөбәтуллина Зөлфия Мәүлет кызы | Район Башкарма комитетының эшләр идарәчесе - комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары | |
| Гайнуллин Фәнис Рафик улы | район Советының оештыру бүлеге башлыгы |
| Рунова Татьяна Викторовна | район Советының юридик бүлеге башлыгы |
| Харисов Радик Рәвхәт улы | финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Шәрифуллин Рәсим Гариф улы | коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча район Башлыгы ярдәмчесе |